ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Зеленодольск шәһәре **КАРАР**

**2016 елның 30 мае** **№ 1432**

«2015-2020 елларга Зеленодольск муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Зеленодольск муниципаль районында коррупциягә каршы тору системасын камилләштерү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 05 мартындагы 477 номерлы «2015 - 2020 елларга Зеленодольск муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасын раслау турында» карары белән расланган «2015 - 2020 елларга Зеленодольск муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1) «Программаның төп эшләүчеләре» юлында муниципаль программа паспортының «Зеленодольск муниципаль районында коррупциягә каршы тору комиссиясе» сүзләрен «Зеленодольск муниципаль районында коррупциягә каршы тору буенча координацияләү комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

2) «IV. ПРОГРАММА МЕХАНИЗМЫН ГАМӘЛГӘ АШЫРУ» бүлегендә «Зеленодольск муниципаль районында коррупциягә каршы тору комиссиясе» сүзләрен тиешле килештә «Зеленодольск муниципаль районында коррупциягә каршы тору эшен координацияләү буенча комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

3) «2015-2020 елларга Зеленодольск муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасының максаты, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары» кушымтасында:

3.1) таблицаның 1 пунктында:

3.1.1) 1.3 пунктчасында «ЗМР коррупциягә каршы тору комиссиясе» сүзләрен «ЗМР коррупциягә каршы тору эшен координацияләү буенча комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

3.1.2) 1.3 пунктчасыннан соң түбәндәге эчтәлекле 1.3.1 пунктчасы өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «1.3.1. ЗМР коррупциягә каршы тору эшен координацияләү буенча Комиссиясе эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру буенча чаралар күрү»; | ҖҮО (килешү буенча) | 2016-2020 еллар; | | | | | | | | | | | | | |

3.2) таблицаның 4 пунктында:

3.2.1) 4.4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «4.4. Устав бурычы булып коррупциягә каршы торуда, иҗтимагый советларда һәм гражданлык җәмгыяте институтларында, муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән тыюларны, чикләүләрне һәм таләпләрне үтәү буенча оештыру, аңлату һәм башка чаралар комплексы, шул исәптән бүләкләр алуга, бүтән түләүле эш башкаруга кагылышлы, коррупцион хокук бозулар кылуга тарту максатларында мөрәҗәгатьләр турында хәбәр итү бурычы торган җәмәгать берләшмәләре катнашында эшләү һәм аларны гамәлгә ашыру»; | ҖҮО (килешү буенча) | 2015-2020 еллар; | | | | | | | | | | | | | |

3.2.2) 4.5 пунктчасыннан соң түбәндәге эчтәлекле 4.6 пунктча өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «4.6. Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органнарында, муниципаль учреждениеләрдә һәм гамәлгә куючы булып Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тора торган | ҖҮО (килешү буенча) | 2016-2020 еллар; | | | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| район предприятиеләрендә коррупцияне кисәтү эшләрен башкару»; | | | | | | | | | | | | | | | | |

3.3)Таблицаның 5 пунктның 5.9 пунктчасыннан соң түбәндәге эчтәлекле 5.10 пунктча өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «5.10. Урман-парк һәм су саклау зоналарын законсыз файдалануга һәм төзүгә бәйле хокук бозуларны ачыклау өчен халыкны җәлеп итү максатларында “Халык инвентаризациясе” акциясе үткәрү. Ачыкланган хокук бозуларны булдырмау һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү өчен чаралар күрү»; | ҖҮО (килешү буенча) | 2016-2020 еллар; | | | | | | | | | | | | | | |

3.4) таблицаның 8 пунктында :

3.4.1) 8.2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «8.2. Муниципаль хезмәттә мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу турындагы законнарның таләпләрен үтәүне тәэмин итү: муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәү очракларын ачыклау эшләрен башкару; күрсәтелгән таләпләрне үтәмәүнең һәр очрагын игълан итү; әлеге таләпләрне бозучы затларга карата законнарда каралган юридик җаваплылык чараларын куллану. Бу эшнең торышы һәм аны камилләштерү буенча ЗМРда коррупциягә каршы тору эшен координацияләү буенча комиссиясе утырышларында ел саен фикер алышуны тәэмин итү»; | ЗМРда КК тору буенча комиссия, ҖҮО кадрлар хезмәтләре (килешү буенча) | 2016-2020 еллар; | | | | | | | | | | | | | | |

3.4.2) 8.2 пунктчасыннан соң түбәндәге эчтәлекле 8.3 пунктчасы өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «8.3. Коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән чикләүләрне һәм таләпләрне үтәмәгән һәр очракта законнарда каралган юридик җаваплылык чараларын куллануны тикшереп торуны тәэмин итү»; | ЗМРда КК тору буенча комиссия, ОМС кадрлар хезмәтләре (килешү буенча | 2016-2020 еллар; | | | | | | | | | | | | | | |

4) файдаланылган кыскартулар исемлегендә «Зеленодольск муниципаль районында коррупциягә каршы тору буенча комиссиясе - ЗМР КК тору буенча комиссиясе» сүзләрен «ЗМР КК тору буенча комиссиясе-«Зеленодольск муниципаль районында коррупциягә каршы тору эшен координацияләү буенча комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга.

2. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге башлыгы А.Н.Коршуновка әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә урнаштыруны тәкъдим итәргә.

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе А.Х. Сәхибуллин